СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**2019 ел** 24 **октябрь** **№** 278

**. Арча район Советының 2011 елның 31 гынварындагы 31.3 номерлы карары (2013 елның 27 декабрендәге 243.1 номерлы, 2014 елның 6 маендагы 268 номерлы, 2016 елның 19 февралендәге 34 номерлы, 2016 елның 7 апрелендәге 46 номерлы, 2017 елның 28 апрелендәге 126 номерлы, 2019 елның 20 августындагы 262 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппараты турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппараты структурасын камилләштерү, Арча муниципаль районы җирле үзидарә органы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатында, Арча район Советы **карар бирде**:

1. Арча район Советының 2011 елның 31 гынварындагы 31.3 номерлы карары (2013 елның 27 декабрендәге 243.1 номерлы, 2014 елның 06 маендагы 268 номерлы, 2016 елның 19 февралендәге 34 номерлы, 2016 елның 07 апрелендәге 46 номерлы, 2017 елның 28 апрелендәге 126 номерлы, 2019 елның 20 августындагы 262 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппараты турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.

-Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппараты структурасыннан:

опека һәм попечительлек секторын;

баш белгеч (тәрҗемәче);

-Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппаратының гомуми оштыру бүлеге структурасыннан:

мәгълүмат-коммуникация технологияләре һәм мәгълүматны яклау секторын;

архив эшләрен исәпкә алу һәм алып бару секторын чыгарырга.

1.2. Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппараты структурасына:

-опека һәм попечительлек бүлеген;

- архив эшләрен исәпкә алу һәм алып бару бүлеген;

-мәгълүмат-коммуникация технологияләре һәм мәгълүматны яклау секторын;

- кадрлар секторын кертергә.

2. Әлеге карарның 1 пунктына кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, «Аппарат структурасы» дигән 3 статьяның 3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Муниципаль район башкарма комитеты аппараты үз эченә ала:

1. Башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе.

2. Гомуми оештыру бүлеге:

3. Архив эшләрен исәпкә алу һәм алып бару бүлеге;

4. Инфраструктура үсеше бүлеге:

- шәһәр төзелеше һәм архитектура секторы;

- ТКХ, энергетика һәм элемтә секторы.

5. Икътисад һәм финанслар бүлеге.

6. Бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлеге

7. Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге.

8. ГХАТ бүлеге.

9. Опека һәм попечительлек бүлеге.

10. Мәгълүмат-коммуникация технологияләре һәм мәгълүматны саклау секторы.

11. Кадрлар секторы.

12. Әйдәп баручы белгеч.

Башкарма комитет аппараты хезмәткәрләре саны башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан раслана».

3. Әлеге карарны Арча муниципаль районының рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибе һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе                                        И.Г.Нуриев